**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 29.08.2022** **№ 851**

## 16:16:215801:3477, 16:16:215801:3478, 16:16:215801:3479 кадастр номерлы җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Семиозерка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге 16:16:215801:3477 кадастр номерлы, 4864 квадрат метр мәйданлы; 16:16:215801:3478 кадастр номерлы, 15000 квадрат метр мәйданлы; 16:16:215801:3479 кадастр номерлы, 3376 квадрат метр мәйданлы җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен «индивидуаль торак төзелеше өчен» төреннән «Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү» төренә үзгәртергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 09 августындагы 787 номерлы һәм 2022 елның 17 августындагы 812 номерлы карарларын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов